КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 15 декабрь г.Казань № 1147

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 сентябрь, 699 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 16 март, 192 нче; 2015 ел, 20 июнь, 445 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне расларга (карарга теркәлә):

Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташуларны тормышка ашыручы транспорт чаралары китерә торган зарар күләме күрсәткечләре;

Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташуларны тормышка ашыручы транспорт чаралары китерә торган зарар күләмен исәпләү.»;

әлеге карарга кушымта үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карарга Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташуларны тормышка ашыручы транспорт чаралары китерә торган зарар күләмен һәм Татарстан Республикасында төбәк яки муниципальара әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташуларны тормышка ашыручы транспорт чаралары китерә торган зарар күләмен исәпләүне өстәргә (теркәләләр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин